ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 194

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларын тәэмин итү максатыннан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
13.04. 2020
194 номерлы карарына кушымта

**Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибе**

1. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибе (алга таба - Тәртип), 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 5 ст., 9 ст. 1 пунктын үтәп, мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә (алга таба - Учреждениеләр) тәрбияләнүчеләрнең хокукларын тәэмин итү максатыннан эшләнде.

2. Учреждениегә тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору (алга таба - кабул итүне туктату) Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Учредитель) карары буенча гамәлгә ашырыла.

3. Кабул итүне туктату сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: Учреждениегә капиталь ремонт ясау вакыты, җәйге чор (аз комплектлы Учреждение өчен генә), тәрбияләнүчеләрнең һәм персоналның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар, шулай ук Учредитель карары буенча башка сәбәпләр.

Кабул итүне вакытлыча туктату түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

- Учреждениедә капиталь ремонт эшләрен уздырган чорда - Учредительнең шәхси карары буенча;

- җәйге чорда - җәйге чорда Учреждение эше турында ата-аналар җыелышы карары нигезендә;

- Роспотребнадзор, Дәүләт янгын күзәтчелеге органнары һәм башкалар белән килештереп, куркынычсызлыкны һәм персоналны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар уздыру чорында;

- башка сәбәпләр барлыкка килү очракларында - тиешле структуралар, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килештереп (кирәк булганда).

5. Ата-аналар җыелышының Учреждениенең җәйге чорда эше турындагы карарында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарының (законлы вәкилләренең) кабул итүне туктатып тору турындагы үтенечнамәсе;

- тәрбияләнүчеләрне кабул итүне туктатып тору күздә тотыла торган вакыт турындагы мәгълүмат;

- һәр тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) күрсәтелгән срокларда мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрендә ихтыяҗ булмау турында карары.

6. Ата-ананың (законлы вәкилнең) берәрсе генә җәйге чорда кабул итүне туктатып тору белән килешмәсә дә, Учредительгә үтенечнамә бирелми һәм аның буенча карар кабул ителми.

7. Тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарының (законлы вәкилләренең) мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗы булган очракта, кабул итү туктатылганда, Учреждениедә тәрбияләнүчегә ата-анасы (законлы вәкиле) ризалыгы белән беркетелгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә урын бирелергә тиеш (кушымта).

8. Әгәр аларга карата ата-аналар (законлы вәкилләр) әлеге Тәртип тарафыннан билгеләнгән вакытлыча күчерүгә ризалык биргән барлык тәрбияләнүчеләр дә кабул итүче Учреждениеләрдә урыннар белән тәэмин ителмәсә, Учреждениене планлы туктатып тору башкарылмый.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибенә кушымта

Эшчәнлекне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен беркетү

| т/б № | База МБУ | Беркетелә торган МБУ |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Миләшкәй» Олы Кайбыч балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Кайбыч «Сандугач» балалар бакчасы» МБМББУ<br>2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Чәчкаб балалар бакчасы» МБМББУ<br>3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти «Буратино» балалар бакчасы» МБМББУ<br>4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән «Аленушка» балалар бакчасы» МБМББУ<br>5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит «Гөлбакча» балалар бакчасы» МБМББУ<br>6. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки «Чулпан» балалар бакчасы» МБМББУ<br>7. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай балалар бакчасы» МБМББУ<br>8. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Тәрбит «Карлыгач» балалар бакчасы» МБМББУ |
| 2. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Тиенкәй» Кошман балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле «Ромашка» балалар бакчасы» МБМББУ<br>2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Зур Русак «Чулпан» балалар бакчасы» МБМББУ |

| | | |
|---|---|---|
| | | 3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино «Земляничка» балалар бакчасы» МБМББУ<br>4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково «Солнышко» балалар бакчасы» МБМББУ |
| 3. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Теремок « Федоровский балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы «Кояшкай» балалар бакчасы» МБМББУ;<br>2.»Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәме «Ромашка» балалар бакчасы» МБМББУ<br>3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье «Каенкай» балалар бакчасы» МБМББУ<br>4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык «Гөлбакча» балалар бакчасы» МБМББУ |